*Шакурова М. М. (КФУ, Казань),*
*Юсупова З. Ф. (КФУ, Казань)*

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ИКЕТЕЛЛЕЛЕК ШАРТЛАРЫНДА ТАТАР ҺӘМ РУС ТЕЛЛӘРЕНЕҢ БӘЙЛӘНЕШЕ (ФОНЕТИК АСПЕКТ)

**Аннотация:** Цель статьи – провести анализ сопоставительных исследований на материале татарского и русского языков в условиях двуязычия РТ, выявить сходства и расхождения на фонетическом уровне, предложить методические рекомендации для успешного усвоения фонетики татарского языка.

**Ключевые слова:** двуязычие, русский язык, татарский язык, сопоставление, фонетический аспект.

**Tatar-Russian language relations in conditions of bilingualism of the Republic of Tatarstan (phonetic aspect)**

**Abstract:** The purpose of the article is to analyze comparative studies on the material of the Tatar and Russian languages in conditions of bilingualism of the RT, to identify similarities and differences at the phonetic level, to offer methodological recommendations for the successful mastering of the phonetics of the Tatar language.

**Key words:** bilingualism, Russian language, Tatar language, juxtaposition, phonetic aspect.

Татарстан Республикасында икетеллелек шартларында татар һәм рус телләрен чагыштырма планда өйрәтү бүгенге көндә иң актуаль мәсьәләләрдән берсе булып тора. «Татарстан Республикасы Халыклары телләре турында» гы закон һәм Дәүләт программасы мәктәпләр, балалар бакчалары, колледжлар, югары уку йортлары алдында да зур бурыч куйды. Әлеге мөһим карарны хәл итүдә гомуми белем бирү оешмаларының татар һәм рус теле укытучылары милләтара мөнәсәбәтләрнең үзара ярашып торуына ярдәм иткән милли икетеллелекне формалаштыру буенча төп функцияне тормышка ашыручылар булып тора [4, с. 42].

Татар теле, барлык башка төрки телләр кебек үк, агглютинатив телләргә керә. Сүзнең тамырына аффикслар (кушымчалар) билгеле бер тәртиптә ялганалар (мәсәлән, китап – лар – ым – да). Шуңа бәйле рәвештә җөмләдә сүзләрнең грамматик мәгънәләрен билгеләүдә кыенлыклар тумый.

Теләсә кайсы телне өйрәнергә керешкәнче, иң элек шул телнең фонетик системасын, андагы төп фонетик закончалыкларны белергә, ике тел арасындагы аермаларны яхшы күзаллап, аларны чагыштырып өйрәнергә кирәк [8, с. 211]. Мәктәп дәреслекләрендә тел гыйлеме бүлекләре арасында «Фонетика. Орфоэпия. Графика» дип берләштереп биргән бүлек иң мөһим бүлекләрнең берсе булып санала. Телнең аваз төзелешен өйрәнә торган тармак фонетика (грек. phonetike; phone – аваз, tike караган, бәйле) дип атала. XX гасыр ахырлары XXI гасыр башларында «Фонетика» курсын җентекләп өйрәнгән галимнәр арасында Х.Х.Сәлимов, Ф.М. Хисамова, Г.М. Сөнгатов, Ф.С. Хәкимҗанов, Г.К. Хадиеваларны атап үтәсе килә. Авторлар фонетикада сөйләм авазларын өч аспекттан чыгып өйрәнәләр [3]:

| Сөйләм авазлары | | |
|---|---|---|
| Физиологик аспект | Физик яки акустик аспект | Лингвистик яки функциональ аспект |
| Авазларны әйтүдә сөйләм органнарының (үпкәләр, тын юлы, бугаз, тавыш ярылары, йоткылык, тел, кече тел h.б.) кайсылары һәм ничек катнашулары карала. | Авазлар бер физик күренеш буларак (һава дулкыннарының тирбәнеше буларак) тикшереләләр. | Аваз кешенең фикерен чагылдыруда, мәгънә белдерүдә дә катнаша. |

Сөйләм авазлары әдәби телдә дөрес сөйләү, телләрне чагыштырып өйрәтүдә бик кирәк. Фонема – сүзләрне һәм кушымчаларны төзи торган, аларны бер-берсеннән аеру өчен хезмәт иткән иң кечкенә аваз берәмлеге. [6, 18] Фонема һәрвакыт үзгәрештә була. Фонема – мәгънәне ясый һәм аны аера торган берәмлек. Мәсәлән: кол (раб) – кул (рука) – күл (озеро) – көл (зола).

Аваз – сөйләмнең таркалмый торган иң кечкенә берәмлеге: [а], [г], [п] һ.б. Рус телендә алты сузык аваз бар: [и], [ы], [у], [е], [о], [а]. Татар телендә 12 сузык аваз бар, шуларның тугызы татар сүзләрендә, өчесе рус теленнән һәм рус теле аша башка Европа телләреннән кергән алынма сүзләрдә кулланыла: [о], [ы], [э(е)]. Әлеге авазлардан башка барлык татар сүзләрендә кулланылган сузык авазлар нечкә сузыкларга (алгы рәт сузыклары) һәм калын сузыкларга (арткы рәт сузыкларына) бүленәләр: [а] - [ә], [у] - [ү], [ы] - [э (е)], [о] - [ө], [и]. Гарәп алынмаларында калын тартыклардан соң килгән [и] сузыгы татар телендә [ый] белән белдерелә, ягъни [и] авазының калын пары булып [ый] авазы тора дигән фикерләр дә бар: Фатыйма, Фатыйх, вазыйфа, хасыйл һ.б. [5, 36] Ләкин соңгы елларда рус теле йогынтысында татар урта гомуми белем бирү оешмаларында укучы балаларның, яшьләрнең сөйләмендә [и] авазын кирәгеннән артык нечкәртеп әйтү колакка чалына башлады: [ә т и`] (этиь), [ә н и`] (әниь) һ.б.

Рус теленнән аермалы буларак, сингармонизм законы – төрки телләрнең барысына да хас булган төп үзенчәлек, ягъни ул сузык авазларның ярашуын белдерә. Сингармонизм законының ике төре була: 1) рәт гармониясе һәм 2) ирен гармониясе. Рәт гармониясе - бер сүз эчендә авазларның я калын, я нечкә генә әйтелүе: ба-ла-лар-ның, тә-рә-зә-ләр-не. Ирен гармониясе – беренче иҗектә [о] һәм [ө] авазлары бар икән, шуннан соң килә торган иҗекләрдәге [ы], [е] сузыкларының иренләшүе: сөлге – [с ө л г ө], борынгы [б о̆ р о̆ ң ғ ы].

Ләкин биредә чыгармаларны истә тотарга кирәк: беренчесе – алынма сүзләрдә (бигрәк тә гарәп-фарсы, рус сүзләрендә) бу закон үтәлмәскә дә мөмкин. Мәсәлән: китап, мөгаллим, телевизор һ.б. (Искәрмә, рус теленнән гади сөйләм аша кергән сүзләр сингармонизмга буйсынганнар: өстәл, мунчала, бүрәнә, ужым, эшләпә һ.б.). Икенчесе – татар телендәге кайбер сүзләрнең сингармонизм законына буйсынмаган очраклары да бар: кушма сүзләр (Гөлнур, көнбагыш,

көнчыгыш), кайбер зат алмашлыклары (миңа, сиңа), сүзләргә -су кышымчасы ялганган очраклар (зәңгәрсу, көлсу). [6]

Татар алфавиты рус графикасына нигезләнә, 39 хәрефтән тора. Анда рус алфавитындагы 33 хәрефкә татар теленең үзенчәлекле авазларын белдерүче 6 хәреф өстәлгән: а, ө, ү, җ, ң, һ. Татар телендә 28 тартык аваз бар: [б], [п], [в], [ф], [г], [ғ], [к], [қ], [д], [т], [ж], [ш], [з], [с], [җ], [ч], [л], [м], [н], [ң], [й], [р], [w], [ц], [щ], [х], [һ], [’].

Шунысы да игътибарга лаек: татар телендә [ғ], [қ] [’], [w] авазларын белдерү өчен махсус хәрефләр булмау башка төрки халык вәкилләренә телне өйрәнүдә кыенлык тудыра (Гата, кара, тәэсир, авыл). Һәмзә [’] – татар телендәге үзенчәлекле тартык аваз. Ул нигездә гарәп алынмаларында кулланыла. Язуда өч төрле хәреф белән билгеләнә: э (тәэсир, тәэмин), ь (мәсьәлә), ъ (Коръән).

[w] авазы язуда өч төрле хәреф белән белдерелә: 1) сүз һәм иҗек башында килгәндә, в хәрефе белән: вакыт [wакыт], авыл – [аwыл]; 2) калын иҗек ахырында у хәрефе белән: тау – [таw]; 3) нечкә иҗек ахырында ү хәрефе белән: дәү [дәw]. Шул ук вакытта алынма сүзләрдә в хәрефе [в] авазын белдерә: вагон, визит, вариант һ. б.

Татар телендә сүз азагында к, г, п тартыклары сузык аваз өстәлгәндә яңгыраулашалар: ак – ага, түк - түгә, тап – таба һ.б. Ләкин рус теле аша үтеп кергән күп кенә алынмаларда бу принцип үтәлми: темп – темпы, текст – тексты, банк – банкы, отпуск - отпускы һ.б. Мәсәлән: Мине җәйге ялга - отпускыга җибәрүегезне үтенәм. [7, 48] Ж – татар теленең үз сүзләрендә бик сирәк кулланыла (гөж килә, гөжелдәп куя һ.б.), нигездә алынмаларда язылa (жираф, жанр һ.б.). Ц, щ – татар сүзләрендә кулланылмый (цирк, щетка һ. б.).

Гарәп теленнән кергән һ һәм х хәрефләрен язуның аерым кагыйдәләре юк, [h] авазын рус теле йогынтысында [х] дип әйтү киң таралган: хәм - һәм, шәхәр – шәһәр һ.б. (һәм, шәһәр, һәлак, хат, һәркем, хата, хәтта, хәзер, шәхси, һава һ.б.).

Әлеге бүлектә басым, интонация дә җентекләп карала. Басым - сүзнең бер иҗеген башкаларыннан аерып әйтү ул. Рус теленнән аермалы буларак, татар телендә басым тотрыклы, гадәттә ул сүзнең ахыргы иҗегенә төшә. Сирәк булса да басым сүзнең беренче, икенче иҗекләренә дә төшәргә мөмкин. [1] Татар теле дәреслекләрендә басым белән бәйле чыгармалар башлангыч сыйныфтан башлап югары сыйныфларга кадәр ассызыклап барыла:

| Кагыйдә | Мисаллар |
|---|---|
| Фигыльдә юклык кушымчасы басымны алмый һәм үзеннән соң үткәрми. | Укымагансың, килмәде, сөйләми. |
| Басым сүзнең ахыргы иҗегенә төшә. | Башладылар, өстәлдә, агачлар. |
| Рәвеш ясагыч -дай/-дәй, -тай/-тәй, -ча/-чә кушымчалары басымны үзләренә алмыйлар. | Аюдай, бөркеттәй, татарча. |
| Басым сүзнең беренче иҗегенә төшә. | Укыгыз, утыр, җырлагыз. |
| Парлы сүзләрдә басым беренче сүзнең соңгы иҗегенә төшә. | Бала-чага, хатын-кыз, урын-җир. |
| Сорау алмашлыкларында басым беренче иҗеккә төшә. | Нинди, кайсы, нәрсә. |
| Сыйфатлар алдыннан килгән көчәйткеч кисәкчәләр басымны үзләренә алалар. | Иң матур, кап-кара, сап-сары. |

Басымның төрләре: сүз басымы (сүзнең бер иҗеген башкаларыннан аерып әйтү), логик басым (сөйләмдәге бер сүзнең башкаларыннан аерылып торуы), синтагма басымы (сөйләмнең интонацион-мәгънәви кисәкләренә төшүе), тойгы басымы (эмфатик басым, ягъни ярату, мыскыллау, нәфрәт һ.б белдерү). Мәсәлән, синтагма басымына бер мисал карап китик: Әмма кемдер, башка чит бер кеше, аның туган нигезенә йорт салып чыгар дип, башына да китермәде. (Р. Мөхәммәдиевтән) - Әмма кемдер, / башка чит бер кеше, / аның туган нигезенә / йорт салып чыгар дип, / башына да китермәде.//

Фонетика бүлеген өйрәнгәндә, татар телендәге җөмләләрне, тойгы басымын куеп, дөрес интонация белән укып күрсәтү дә бик мөһим. Мәсәлән: Мияубикә талга кунган бөтен кош-кортларга сөрән салды. (Р.Хафизова) – Мияубикә талга кунган бөтен кош-кортларга сөрән салды! (Көчле тойгы белән укыгыз). Мияубикә талга кунган бөтен кош-кортларга сөрән салды? (Сорау интонациясе белән укыгыз). Мияубикә талга кунган бөтен кош-кортларга сөрән салды. (Ярату төсмере белән укыгыз). Мияубикә талга кунган бөтен кош-кортларга сөрән салды. (Мыскыллау төсмере белән укыгыз).

Калын хәрефләр белән бирелгән сүзләргә логик ба-

сымны куеп, җөмләләрне дөрес итеп укыту да зарур. Мәсәлән: Борһан абзый быел кыш Хәятны биш-алты ай русча да укытты. (Ф.Әмирхан) - Борһан абзый быел кыш Хәятны биш-алты ай русча да укытты. Борһан абзый быел кыш Хәятны биш-алты ай русча да укытты. Борһан абзый быел кыш Хәятны биш-алты ай русча да укытты. Борһан абзый быел кыш Хәятны биш-алты ай русча да укытты. Борһан абзый быел кыш Хәятны биш-алты ай русча да укытты.

Татар һәм рус телләрендә интонация сөйләмне җөмләләргә бүлә, җөмлә төрләрен оештыруда катнаша, сөйләүченең халәтен белдерә. Интонация – тавышның төрлечә хәрәкәт итүе ул. Телне өйрәткәндә сөйләмдә интонациянең компонентларына – тавышның көе, тавышның көче, сөйләм тизлеге, паузалар, тавышның тембрына аеруча игътибар итәргә кирәк. [9]

Ике телне чагыштырганда орфоэпия (грек. orthos - дөрес, epos - сөйләм) – дөрес әйтелеш кагыйдәләре җыелмасы да үзәктә тора. Әдәби әйтелеш ике төргә бүленә: тулы стиль, сөйләшү стиле. Тулы стиль радиотапшыруларда, доклад, чыгыш ясаганда кулланыла. Тулы стильдә сүзләр, иҗекләр ачык итеп әйтелә. Сөйләшү стилендә кайбер иҗекләр кыскара, төшеп кала, диалектларның йогынтысы зур була. Татар телендә орфоэпик нормаларның бозылуы нигездә өч сәбәп аркасында була [3]: 1) әйтелеш белән язылыш арасында зур аерма булу: гомер [гъ ө м ө р], канәгать [къ ә н ә гъ ә т], кыйммәт [къ и м м ә т] һ.б.; 2) әдәби телгә диалекталь тәэсир зур булу: җегерме (егерме), бәк матур (бик матур), әчкеч (ачкыч), назан (надан), телке (төлке), пыцак (пычак), баргандагын (барган да), баргачтын (баргач) һ.б.; 3) әдәби әйтелешкә рус теле һәм рус теле аша кергән башка телләрнең тәэсире зур булу: Яңа чорлар килде. Радио-телевидение, компьютер, Интернет заманы. Техника, электроника үзгәрә, компьютерлар, телефоннар, телевизорлар, музыка тыңлый торган төрле аппаратуралар яңара, камилләшә. Уены да шунда, дәреслекләре дә, фильмнары да, музыкасы да, фотосурәтләре дә, хәтта шпаргалкалары да... (Р. Миңнуллин)

Телләрне чагыштырып өйрәнгәндә язу — телнең график формасы, ул аралашу өчен гаять әһәмиятле корал булып торуын да үзәккә алырга кирәк. Рус телендә иң элек сүзләрне морфологик принципка нигезләп язсалар (золотая осень – проверяющее слово – зо`лото [з а л а т а й а о` с э н’]), татар телендә исә фонетик принципка нигезләп

язалар (идән, тәрәзәләр һ.б.). Орфографик принциплар: фонетик (сүзләрне ишетелгәнчә язу), морфологик (сүзләрнең мәгънәле кисәкләрен һәр очракта да бер генә төрле язу), тарихи-традицион (сүзләрне элегрәк кулланганча язу), график (алынма сүзләрне шул телдәгечә язу) принциплар. Хәзерге татар орфографиясендә дифференциацияләнгән язылыш та кулланыла: (өч почмак – өчпочмак, биш бармак - бишбармак һ.б.).

Шулай итеп, татар һәм рус телләрендәге авазлар системасы, басым, интонация, орфография, орфоэпия өлкәсендәге кайбер үзгәрешләр сөйләмне аңлауда, телне өйрәнүдә авырлыклар тудыра. Шул сәбәпле татар яки рус телен җентекләп өйрәтүгә керешкәнче аның структурасына, бигрәк тә фонетика, лексика һәм грамматик төзелешенә хас булган үзенчәлекләрне, төп кагыйдәләрне үзләштерү бик мөһим.

Әдәбият:

1. Мирзаһитов Р.Х. Татар теле. 9 сыйныф: рус телендә гомуми блем бирү оешмалары өчен уку әсбабы (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) Р.Х. Мирзаһитов, М.М. Шәкүрова, Н.Х. Мусаяпова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2017. – 190 б.

2. Салимов Х.Х. Просодическая система татарского языка: Автореферат дис. ... д-ра филол. наук. – Казань, 1999. – 64 с.

3. Салимов, Х.Х., Салимова Д.А. Сопоставительная фонетика татарского и русского языков (в таблицах, схемах, упражнениях): Учебное пособие для студентов вузов. – Елабуга, 2007. – 80 с.

4. ТР халыклары телләре турындагы РТ законы. ТР халыкларының телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча ТР Дәүләт программасы.– Казан: ТР-сы Дәүләт Советы басмасы, 1996.

5. Хәкимҗанов Ф.С. Татар теле: Фонетика. –Казан:ТДГИ нәшр., 2001.–108 б.

6. Хисамова Ф.М. Хәзерге татар әдәби теле фонетикасы. Офсет, лаб. Казан, ун-та, 1987

7. Хөснетдинов Д.Х., Шәкүрова М.М. Татар теленең графикасы һәм орфографиясе: Методик кулланма / Д.Х.Хөснетдинов, М.М.Шәкүрова. – Казан: КФУ, 2015. – 74 б.

8. Шакурова М.М. Татарско-русское двуязычие: проблемы обучения языкам // Филологические науки. Вопросы теории и практики Philological Sciences. Lssues of Theory and Practice.

Тамбов: Грамота, 2016. № 10. Ч. 2 С. 211-214.

9. Шанский Н.М., Тихонов А.Н. Современный русский язык: Учебник для студентов пед. ин-тов / Н.М.Шанский, А.Н.Тихонов. – М.: Просвещение, 1981.

10. Юсупова З.Ф. Сопоставительно-типологическиое исследование разноструктурных языков в аспекте совершенствования методики преподавания русского языка как неродного / Русский язык в поликультурном пространстве: монография. – М.: РосНОУ, 2014. – С.293-320.